**СОВЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Тататрстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2021 елның 24 ноябреннән № 15-109

«2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге план чорына Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше стратегиясе»н 2021 елда гамәлгә ашыруның барышы һәм 2022 елга бурычлар турында»

Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары Исхакова Луиза Камил кызының «2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге план чорына Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше стратегиясе»н 2021 елда тормышка ашыруның барышы һәм 2022 елга бурычлар турында» докладын тыңлаганнан һәм тикшергәннән соң, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары Л. К. Исхакованың «2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге план чорына Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше стратегиясе»н 2021 елда тормышка ашыруның барышы һәм 2022 елга бурычлар турында» мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты, Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнары, район предприятиеләре һәм оешмаларына тәкъдим итәргә:

- эшкуарлык эшчәнлеген алып бару өчен уңай шартлар тудыруга, инвестиция проектларны гамәлгә ашыру өчен дәүләт һәм шәхси инвестицияләрне җәлеп итүгә, төп капиталга инвестицияләрне арттыруга ярдәм итәргә;

- авыл җирлекләренең тотрыклы үсешенә, Яңа Чишмә муниципаль районы халкының мәшгульлеген һәм тормыш дәрәҗәсен күтәрүгә ярдәм итәргә;

-беренчел медик-санитар ярдәм күрсәтүче медицина оешмаларының халык өчен оптималь үтемлелеген тәэмин итәргә, күрсәтелгән медицина оешмаларына

гражданнар мөрәҗәгать иткәндә чират көтү вакытын кыскартырга, табибка язылу процедураларын гадиләштерергә.;

- халыкның барлык категорияләре һәм төркемнәре өчен физик культура һәм спорт, массакүләм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудырырга;

- төп гомуми һәм урта гомуми белем баскычларында укыту һәм тәрбиянең яңа методларын, укучыларның база күнекмәләрен үзләштерүне тәэмин итә торган белем бирү технологияләрен гамәлгә кертергә, аларның белем алуга мотивациясен арттыру һәм белем бирү процессына җәлеп итәргә, шулай ук «Технология» фәне өлкәсендә эчтәлекне яңартырга һәм укыту методларын камилләштерергә;

- хезмәткәрләрнең хезмәт хакын арттыруга һәм аны легальләштерүгә ярдәм итәргә;

- район халкына мәдәният өлкәсендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең үтемлелеген һәм сыйфатын арттырырга;

- 2022 елда һәм аннан соңгы елларда «2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге план чорына Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше стратегиясе»н уңышлы гамәлгә ашыруга ярдәм итә торган төп күрсәткечләргә ирешергә.

3. Әлеге карарны Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә)

4. Әлеге карарны тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципаль район башлыгы В. М. Козлов